**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2021 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Яхшы-Бай авыл җирлеге Мәсгут торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**22 ноябрь 2020 ел** **№ 2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәсгут авыл җирлеге Яхшы-Бай торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2021 елда 1 торкем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 200 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Яхшы-Бай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- Яхшы-Бай авылы зират территориясендә корыган агачларны кисү.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Яхшы-Бай авылы Мәсгут авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче
Азнакай муниципаль районы
Мәсгут авыл җирлеге башлыгы Э.Ә.Габдрахманов